**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"15" ноябрь 2023 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Иске Өҗем торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районың Өҗем авыл җирлеге территориясендә 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрбиләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Иске Өҗем торак пункты территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачлар һәм куаклар кисү, үләннәр чабу, транспорт хезмәтләре һәм эш өчен түләү);

2) Иске Өҗем торак пунктының юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, урам юлларын ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү);

3) Төзелеш материаллары, янгын гидранты сатып алу, аны урнаштыру өчен эш һәм хезмәтләр өчен түләү– мәсьәләсен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Иске Өҗем авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Өҗем авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өҗем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.